ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 18 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 1 – 2, № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 3, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 87 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяда:
а) 1 өлештә:
$1^1$ пунктта «спорт төрләрен» сүзләрен «Россия Федерациясендә спорт төрләрен» сүзләренә алмаштырырга;
түбәндәге эчтәлекле $1^2$ – $1^3$ пунктлар өстәргә:
«$1^2$) Татарстан Республикасында спорт төрләрен үстерү программаларын раслау һәм аларны гамәлгә ашыруда катнашу;
$1^3$) республика спорт федерацияләре тарафыннан Татарстан Республикасында спорт төрләрен үстерү программаларын әзерләү һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органына тапшыру тәртибен билгеләү;»;
3 пунктта:
«б» – «г» пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«б) Татарстан Республикасының рәсми физкультура чараларының һәм спорт чараларының календарь планнарын әзерләү һәм раслау тәртибен, шул исәптән физкультура чараларын һәм спорт чараларын әлеге календарь планнарга кертү тәртибен билгеләү;
в) ел саен Татарстан Республикасы территориясендә үткәрелә торган әһәмиятле рәсми физкультура чараларының һәм спорт чараларының исемлеген булдыру һәм раслау;
г) Татарстан Республикасының рәсми физкультура чараларының һәм спорт

чараларының, шул исәптән «Хезмәткә һәм спортка әзер» Бөтенроссия физкультура-спорт комплексын (алга таба – ГТО комплексы) гамәлгә ашыру буенча физкультура чараларын һәм спорт чараларын үз эченә алганнарның календарь планнарын раслау һәм гамәлгә ашыру;»;

түбәндәге эчтәлекле «д» – «ж» пунктчалар өстәргә:

«д) Татарстан Республикасының календарь планнарына кертелгән рәсми физкультура чараларын һәм спорт чараларын үткәрүгә финанслау һәм акчалар чыгымнары нормалары тәртибен билгеләү;

е) Татарстан Республикасы территориясендә рәсми физкультура чараларын һәм спорт чараларын үткәргәндә җәмәгать тәртибен һәм җәмәгать иминлеген тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү;

ж) төбәк һәм муниципальара рәсми физкультура чараларын һәм спорт чараларын мәгълүмат белән тәэмин итү;»;

түбәндәге эчтәлекле $3^2$ пункт өстәргә:

«$3^2$) Россия Федерациясен, Россия Федерациясе шәһәрләрен халыкара физкультура чараларын һәм спорт чараларын үткәрү хокукына кандидатлар сыйфатында тәкъдим итү чараларын оештыруда, Татарстан Республикасы территориясендә, тиешле халыкара спорт оешмалары тарафыннан билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып, мондый чараларны әзерләүдә һәм үткәрүдә катнашу;»;

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) спорт әзерлегенең республика үзәкләрен төзү, аларның эшчәнлеген тәэмин итү;»;

б) 2 өлештә:

2 пунктта «халыкара спорт ярышларын» сүзләреннән соң «, халыкара физкультура чараларын» сүзләрен өстәргә;

$4^1$ пунктта «халыкара спорт ярышларын» сүзләреннән соң «, студентлар арасында халыкара физкультура чараларын» сүзләрен өстәргә;

2) 12 статьяда 14 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Россия Федерациясе йөкләмәләре барлыкка килә торган халыкара рәсми физкультура чаралары һәм спорт чаралары Татарстан Республикасы территориясендә бары тик мондый чараларны үткәрү турындагы тәкъдимнәрне (гаризаларны) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм физик культура һәм спорт өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы белән килештергәннән соң гына үткәрелә. Мондый чараларны үткәрү турындагы тәкъдимнәрне (гаризаларны) килештерү, мондый чараларны әзерләү һәм үткәрү уңаеннан Россия Федерациясе үзенә ала торган йөкләмәләрне (гарантияләрне) әзерләү, мондый чаралар турындагы нигезләмәләрне (регламентларны) раслау федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

3) 24 статьяның 1 өлешендәге икенче җөмләдә «, тиешле спорт төрләре буенча бөтенроссия спорт федерацияләренең фикерләрен исәпкә алып,» сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 08 апрель
№ 20-ТРЗ